ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «___» июненнән № ____

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2020 елның 11декабрендәге 323 номерлы карары белән расланган «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2020 елның 11декабрендәге 323 номерлы карары белән расланган «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлегендә 2025 елга республика бюджетын түбәндәге эчтәлекле «555,6 мең сум («Сосновка» чаңгы базасын җиһазландыру»)) сүзләрен өстәргә.

«Программаны финанс белән тәэмин итү»нең 6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2 пунктча өстәргә:

«

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең «Сосновка» чаңгы базасын җиһазландыру һәм карап тоту | - | - | - | - | 555,6 | 555,6 |

».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Е.А.Тарнавский